**СОВЕТ**
**АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д. 22,
с. Азеево, 423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы,22 йорт
Акъяр авылы, 423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348)3-7-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы КАРАРы

2020 елның 27 марты — № 65-138

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 2017 ел, 16 март, 23-51 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында" Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 9 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 16.03.2017 ел, № 23-51 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге өстәмәләр кертергә:
2.11 пунктны яңа редакциядә укырга:
«2.6. Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән затлар мәгълүматларны эшкәртәләр һәм реестрларга кертәләр һәм җирле үзидарә органнарындагы муниципаль норматив хокукый актлар текстлары белән бергә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгына җибәрәләр.

Үзгәрешләр кертүче актлар кергәндә, җиде эш көне эчендә үзгәртелә торган муниципаль норматив хокукый актларның актуаль редакцияләре муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру өчен җибәрелә»

- 3.2. пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль норматив хокукый актлар кабул ителгән (бастырып чыгарылган) көннән соң 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару өчен вәкаләтле вәкил тарафыннан җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару өчен вәкаләтле вәкилгә - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгына җибәрелә".

- 3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.3 пункт белән тулыландырырга:

«Муниципаль норматив хокукый акт белән бергә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкилләре тарафыннан муниципаль хокукый актның барлык чыганаклары һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) даталары турында белешмәләр җибәрелә.

Муниципаль норматив хокукый акт Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2016 елның 30 декабрендәге 21-112 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару турындагы Нигезләмәнең 3.2 пунктчасының икенче абзацы нигезендә вәкаләтле органга җибәрелмәгән очракта, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкилләр тарафыннан «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) муниципаль норматив хокукый акт рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән соң 10 эш көне эчендә вәкаләтле органга муниципаль норматив хокукый актны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) даталары һәм барлык башка чыганаклар турында белешмәләр җибәрелә (әгәр мондый белешмәләр әлеге порталда күрсәтелмәгән булса).

Муниципаль норматив хокукый актны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2016 елның 30 декабрендәге 21-112 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.2 пунктчасының икенче абзацындагы вакыт узганнан соң рәсми бастырып чыгарган (халыкка җиткерелгән) очракта, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» pravo.tatarstan.ru бастырып чыгару (халыкка җиткерү) чыганаклары һәм даталары турында белешмәләр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкилләр тарафыннан вәкаләтле органга рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Вәкаләтле орган запросы буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле орган 15 көн эчендә вәкаләтле органга рәсми бастырып чыгару чыганагы булган басма чыганакларда муниципаль норматив хокукый актның үзләре тарафыннан расланган мәкаләләренең күчермәләрен җибәрә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтындагы электрон адрес буенча: http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы Д.С.Гайнуллин